**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР № 289**

**Олы Кайбыч ав.** **21 август, 2015 ел**

**КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ**
**ЭТИКАсы ҺӘМ ХЕЗМӘТ ТӘРТИБЕ КОДЕКСЫНА ҮЗГӘРЕШ КЕРТҮ ТУРЫНДА**

Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 29 ноябрендәге ПУ-1100 номерлы Указы нигезендә һәм муниципаль хезмәттә мәсьәләләрне җайга салуны алга таба камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексын раслау турында» карары белән расланган Кайбыч муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексының 1 статьясы 2 пунктына ««хезмәт эшчәнлеге процессында» сүзләрен «хезмәт эшчәнлеген тормышка ашырганда, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрен кулланып» сүзләренә алмаштырып үзгәреш кертергә.

2. Район җирлекләренең җирле үзидарә органнарына әлеге карарны исәпкә алып муниципаль хезмәткәрләрнең этика һәм хезмәт тәртибе кодексларына үзгәрешләр кертергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының Законлылык һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет Рәисе-**
**Кайбыч муниципаль**
**Районы Башлыгы** **А.И.Рәхмәтуллин**